СОВЕТ ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

03.06.2020 г. Заинск № 530

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмә турында» 2014 елның 14 мартындагы 355 номерлы Зәй муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы белән расланган «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы», «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 27 декабрендәге 118-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә, Зәй муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советы

## КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмә турында» 2014 елның 14 мартындагы 355 номерлы Зәй муниципаль районы Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 42 статьяның 4 өлешендә «2019 елның 1 гыйнвары» сүзләрен «2022 елның 1 гыйнвары» сүзләренә алмаштырырга.

2. Зәй муниципаль районы Советының оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы башлыгы урынбасары В.Г.Акатьевка йөкләргә.

**Совет Рәисе** **Р.Г. Кәримов**